КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 10 июль г.Казань № 563

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 24 декабрь, 1214 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары (муниципаль хокукый актлар) белән каралган, шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең төбәк исемлегенә (классификаторына) үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары (муниципаль хокукый актлар) белән каралган, шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федера-циясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең төбәк исемлегенә (классификаторына) үзгәрешләр кертү турында» 2018 ел, 24 декабрь, 1214 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары (муниципаль хокукый актлар) белән каралган, шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм

Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карама-гындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең төбәк исемлегенә (классификаторына) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 бүлектә:

6.3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «6.3. | Мәгълүмати-телекоммуникация инфраструктурасы компонентларын техник яктан тәэмин итү һәм эксплуатацияләү | элемтә җиһазларының техник әзерлеген, эшләвен тәэмин итү өчен эшләр | | эксплуатация документациясендә билгеләнгән техник таләпләр нигезендә | эш | түләүсез дәүләт эше | 61.10.1; 61.10.4 | 01.01.2019 | 31.12.2099 | Татарстан Республикасы | бюджет | дәүләт хакимиятенең башкарма органы, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы | элемтә җиһазлары урнаша торган объектлар саны, берәмлек | элемтә җиһазларының техник әзерлеге коэффициенты, процент | юк | юк | 1) «Россия Федерациясендә мобилизация әзерлеге һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хәрби вакытның еллык чорына Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына билгеләнгән мобилизация биремнәре турында» 2016 ел, 28 декабрь, 014-1027 нче карары; |

түбәндәге эчтәлекле 6.7 нче пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «6.7. | Мобилизация резервы һәм махсус техника мөлкәтен куркынычсыз саклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру | мобилизация резервының матди кыйммәтләрен җаваплы саклау буенча эшләр | | озак саклау буенча тәгълимнамә нигезендә | эш | түләүсез дәүләт эше | 61.10.1; 61.10.4 | 01.01.2019 | 31.12.2099 | Татарстан Республикасы | бюджет | дәүләт хакимиятенең башкарма органы, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы | мобилизация резервының матди кыйммәтләре саклана торган объектлар саны, берәмлек | мобилизация резервының матди кыйммәтләре коэффициенты, процент | юк | юк | 1) «Россия Федерациясендә мобилизация әзерлеге һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>2) «Дәүләт матди резервы турында» 1994 елның 29 декабрендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон<br>3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хәрби вакытның еллык чорына Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына билгеләнгән мобилизация биремнәре турында» 2016 ел, 28 декабрь, 014-1027 нче карары; |

11 бүлектә:

11.16 нчы пунктның 18 нче графадагы 3 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Юл хәрәкәтен оештыру буенча документлар әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 26 декабрендәге 480 номерлы боерыгы белән расланган Юл хәрәкәтен оештыру буенча документлар әзерләү кагыйдәләре;

11.17 нче пунктта:

3 нче графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Юл хәрәкәтен оештыру буенча документлар әзерләү кагыйдәләре нигезендә юл хәрәкәтен оештыру»;

18 нче графаның 3 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Юл хәрәкәтен оештыру буенча документлар әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 26 декабрендәге 480 номерлы боерыгы белән расланган Юл хәрәкәтен оештыру буенча документлар әзерләү кагыйдәләре;

13 бүлектә:

13.2 нче пунктның 18 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон (19, 20 статьялар);

2) «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (15, 16 статьялар)»;

13.3 нче пунктның 18 нче графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон (19, 20 статьялар);

2) «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (15, 16 статьялар)»;

13.4 нче пунктның 18 нче графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон (19, 20 статьялар);

2) «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (15, 16 статьялар)»;

17 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 17.75 нче пунктча өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «17.75. | Архитектура-төзелеш проектлавын гамәлгә ашыру | күчемсез мөлкәт объектларының проект-смета документларын эшләү | | | эш | түләүсез дәүләт (муниципаль) эше | 74.20 | 01.01.2019 | 31.12.2099 | Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлек | казна | дәүләт хакимиятенең башкарма органы, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы | объектлар саны, берәмлек | | юк | юк | Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы (1 статьяның 16 пункты, 48 статьяның 1 һәм 5 өлешләре)». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин